| СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**29.11.2024** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 170** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә турист салымын кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды**:

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә турист салымын кертергә.

2. Турист салымы ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

- 2025 елда салым базасының 1 проценты күләмендә,
- 2026 елда салым базасының 2 проценты күләмендә,
- 2027 елда салым базасының 3 проценты күләмендә,
- 2028 елда салым базасының 4 проценты күләмендә,
- 2029 елдан башлап салым базасының 5 проценты күләмендә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» һәм «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru)рәсми Порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Совет рәисе** **М.П.Афанасьев**